**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.01.2021 Балык Бистәсе штп. №12пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2021 уку елында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында укучыларны, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда, йөртүне оештыру турында" 2020 елның 8 июлендәге 134 пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

FIAT DUKATO SCB. 23.LMB (транспорт чарасының дәүләт теркәү билгесе: В 970 МВ 116 RUS) маркалы мәктәп автобусын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балыклы Чүкәй урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе балансыннан алып Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “1 нче Балык Бистәсе гимназиясе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе балансына тапшыруга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «1 нче Балык Бистәсе гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең "FORD TRANSIT FBD-EA" маркалы (транспорт чарасының дәүләт теркәү билгесе: АС 395 16 RUS) мәктәп автобусының хәрәкәт маршруты укучылар саны арту сәбәпле үзгәрүенә бәйле рәвештә, 2020 елның 26 һәм 30 июнь көннәрендә маршрутларның юл шартларын тикшерү актлары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 8 июлендәге 134 П номерлы карарына (12.11.2020 елның 12 ноябрендәге, 226 пи номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында карар бирәм:

1. 1 пункт 1.1 пунктчасының 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"-8 нче номерлы маршрут: Балык Бистәсе штп.- икмәк кабул итү предприятиесе (Балык Бистәсе штп)" 2021 елның 1 гыйнварыннан.

2. 1 пунктның 1.1 пунктчасына 22 абзацны өстәргә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“-22 нче номерлы маршрут: Балык Бистәсе-Анатыш авылы” 2021 елның 1 гыйнварыннан.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов